ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
Советы

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Старокамкинского сельского поселения
Алькеевского муниципального района

Адресы: 422897, ТР, Әлки районы,
Иске Камка авылы, Түбән урамы,1 йорт
тел./факс 8(84346) 73-524

Адрес: 422897, РТ, Алькеевский
район, с. Старое Камкино, ул.Нижняя. д.1
тел./факс 8(84346) 73-524

**РЕШЕНИЕ** Иске Камка авылы **КАРАР**

2024 елның 29 июле 90 №

Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 2021 елның 30 нояберендәге «Җир салымы турында» 31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2023 елның 31 июлендәге "Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясының 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында»389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 2021 елның 30 нояберендәге «Җир салымы турында» 31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (яңа ред. 2022.11.04 47 №) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2,3 статьяларда «кадастр хакыннан»сүзләрен төшереп калдырырга;

2 статьяның 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

“-0,3% торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлешеннән тыш) яисә торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата кадастр бәясеннән торак төзелеше (эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)".

4 статьяның 7)подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

7) спорт мәйданчыклары, мәйданчыклар, урамнар, поселок эчендәге юллар, скверлар, бульварлар, һәйкәлләр, су объектлары, су алу корылмалары, су җыю манаралары, суүткәргеч челтәрләре, эчү һәм хуҗалык-көнкүреш билгеләнешендәге объектлар, су белән тәэмин итү челтәрләре, коммуналь хуҗалык объектлары, гидротехник объектлар биләгән гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата муниципаль казна учреждениеләре корылмалары, чистарту корылмалары, каты коммуналь калдыклар урнаштыру урыннары, мәктәпләр, мәктәп кишәрлекләре, шулай ук милектәге, авыл хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукындагы җир кишәрлекләренә карата, җитештерү базалары, фельдшер-акушерлык пункты, балалар бакчасы урнаштыру өчен.

4 статьяның 4)подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

4) шәхси ярдәмче хуҗалык биләгән җир кишәрлекләренә карата җирлек территориясендә эшләүче янгыннан ирекле саклау әгъзалары;

5 статьяга түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә:

"Хисап чоры квартал буларак билгеләнгән салым түләүчеләр агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталлары тәмамланганнан соң салым буенча аванс түләүләре суммаларын җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасының дүрттән бере итеп исәплиләр.

Салым җир кишәрлеге урнашкан урында түләнә.»

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

3. 4 статьяның 7 пунктчасы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 16.05.2024 елның «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 30.11.2021 елның «Җир салымы турында», 31 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында», 85 нче номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми https://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми http:pravo.tatarstan.ru порталында урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге башлыгы — Ф.А.Акберов